Бажуковский филиал  Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение

«Усть – Туркская средняя общеобразовательная школа»

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор МАОУ «Усть-Туркская СОШ» |
| ______/Муртазина | ______/ Аитова Э.Р. | ______/ Юсупова И.Ф. |
| Протокол №1 от «31» августа 2023 г. | «31» августа 2023 г. | Приказ №100 от «31» августа 2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
# ПО РОДНОМУ ЯЗЫКУ
# ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ 7 КЛАССА
# С УМСТВЕННОЙ ОТСТАЛОСТЬЮ

Составитель :

учитель татарского языка и литературы

Шавалиева З.А

с.Бажуки, 2023

## **Аңлатма язуы**

7 нче сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы түбәндәге хокукый-норматив документларга нигезләнеп төзелде:

1) Программа разработана на основе следующих нормативно-правовых документов:
Конституция Российской Федерации;
2) Федеральный закон от 29 декабря 2012 г. № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изменениями и дополнениями);
3)Закон Российской Федерации от 25 октября 1991 г. № 1807-1 «О языках народов Российской Федерации» (с изменениями и дополнениями);
4) Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования (утвержденный приказом Министерства просвещения Российской Федерации от 31 мая 2021 г. № 287);
5) Примерная основная образовательная программа основного общего образования (одобренная решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол № 1/22 от 18 марта 2022 г.);
6) Примерная программа (одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол № 2/220 от 2 июня 2020 г.);
7) Концепция преподавания родных языков народов России (утверждена решением коллегии министерства просвещения РФ от 1 октября 2019 года № ПК-3ВН).

**Дәреслек:** Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф. /Р.К.Сәгъдиева, Г.Ф.Харисова, Л.К.Сабирҗанова, М.Ә.Нуриева.-Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2017. –215 б.

**Максат**:
Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә рус мәктәбендә татар теленә өйрәткәндә укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәниятлелек) компетенцияләр булдыру.

**Бурычлар:**
•укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
•укучыларның сөйләм эшчәнлеген һәм фикерләү сәләтен, төрле шартларда әдәби телдә дөрес аралаша белү күнекмәләрен үстерү;
•татар теле гыйлеме, аның төзелеше, кулланылыш өлкәсе, төп нормалары, сөйләм этикеты, стилистик чаралары белән танышу, сүз байлыгын арттыру;
•тел фактларын анализлый, тел күренешләрен күрә, таба белү сәләтен, тәкъдим ителгән мәгълүматтан мөһимен сайлап ала белү осталыгын үстерү;
•үзләштерелгән белемне һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәтү;
•дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү;

•үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

Предметка **гомуми характеристика** 7нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр

**Морфология:**

1. Сүз төркемнәреннән фигыльне, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәрен, хәбәрлек сүзләрне лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясый белү.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.

**Сөйләм эшчәнлеге:**

1. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белү.
2. Бирелгән план буенча сочинение язу.
3. Әдәби геройларны сурәтләп бирү.
4. Каралган спектакль буенча хикәя төзү (телдән яки язмача).
5. Программа буенча укылган китапның эчтәлеген сөйләү яки язу, үз фикереңне белдерү.
6. Эш кәгазьләреннән белдерү, бәйрәм белән котлау тексты язу.
7. Татарчадан русчага яки русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре эшләү.

**Укыту планында предметның тоткан урыны**

Мәктәпнең укыту планы нигезендә 7 нче сыйныфларда татар теле дәресләрен укытуга атнага 1 сәгать бирелә, ел дәвамында 34 дәрес тәшкил итә, эш программасында да уку елы дәвамында 34 дәрес үткәрү планлаштырыла.

**Предметны үзләштерүнең шәхескә кагылышлы, метапредмет, предмет нәтиҗәләре**

Икенче буын стандартларының нигезен яңа төр мөнәсәбәтләр тәшкил итә:
бүген укучының билгеле бер белем дәрәҗәсенә ия булуын дәүләт кенә түгел, ә бәлки укучы, аның әти-әнисе дә дәүләттән билгеле бер күләмдә сыйфатлы белем бирүен таләп итү хокукына ия.

Икенче буын стандартлары шәхес үсешен тәэмин итү, укытуга үз эшеңне төптән белеп якын килү бурычын куя. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

Нәтиҗәләргә таләпләр –гомуми белем программаларының барлык төрләренең состав өлеше. Алар шәхескә кагылышлы, метапредмет (эшчәнлекнең гомумиләштерелгән ысуллары) һәм предмет буенча (фәнне өйрәнү) нәтиҗәләрне үз эченә ала.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре:**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**:

•татар теленең байлыгын, матурлыгын тоярга өйрәнү, аның чисталыгын саклауга ихтыяҗ булу; туган телне өйрәнүнең әһәмиятен аңлау;

•белем ала белү, тел белеме өлкәсендә белемнәрне мөстәкыйль рәвештә үзләштерү, фәнни-тикшерену эшчәнлеген оештыра белү;

•үзең алган белем күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;-әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;

•үзеңне тыңлаучы күзлегеннән анализлый белү, сөйләмне камилләштерергә омтылу;

•үзбәягә сәләтле булу;
•үз текстларыңны язуга кызыксыну булу.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ):**

•танып-белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм шунан чыгып максатлар кую;
•язма һәм телдән текcттагы мәгълүматны аңлый белү (мөстәкыйль рәвештә текстның темасын, күтәрелгән проблеманы ача белү);
•уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү;
•төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
•төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мөстәкыйль рәвештә мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
•тел берәмлекләрен сөйләм эшчәнлегендә дөрес һәм урынлы файдалана белү, язма сөйләм процессында орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен үтәү;
•билгеле бер темага караган материалны сайлау һәм систeмалаштыру алымнарын үзләштерү;
•тексттан фактик мәгълүматны аерып ала белү;
•телләр арасындагы уртак проблемаларны, уртак кагыйдәләрне, аермалы якларны күрергә өйрәнү;
•сүзлекләр, сүзлекчәләр, белешмә материаллардан файдалана белү;
•телне әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру;
•үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ):**

•сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
•тыңлый белү, диалогта һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
•төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү; үз фикерен тормыштагы мисаллар ярдәмендә дәлилли белү;
•төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
•үз фикереңне язмача һәм телдән тулы һәм төгәл итеп җиткерә белү;
•күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
•мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү;
•укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
•парларда, төркемдә эшли белү;
•башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
•сыйныфташлары каршында төрле темаларга чыгыш ясый белү.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ):**

•мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;

•проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
•максатка ирешү юлларын билгеләү;
•укытучы белән бергәләп яки мөстәкыйль рәвештә үз эшеңне, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
•кагыйдә, күрсәтмәләрдән чыгып эшне оештыру;
•үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзконтроль; эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү;
•биремнәрне үтәүнең дөреслеген бәяләү.

**Предмет буенча нәтиҗәләр:**

•1-5 нче сыйныфларда өйрәнгән фонетик, сүз ясалышы һәм лексик закончалыкларны кабатлау;
• 6 нчы сыйныфта өйрәнгән исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык һәм затланышлы фигыльләрне хәтердә яңарту, аларга хас закончалыкларны тирәнәйтү;
•затланышсыз фигыльләр, аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәрен өйрәнү,
•укылган текстның эчтәлеген аңлау, үз мөнәсәбәтләрен белдерү, укылган текстка бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү, тәкъдим ителгән темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү,-татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итә белү.

**Укучы 7 нче сыйныфны тәмамлаганда сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белем-күнекмәләргә ия булырга тиеш.**

•затланышсыз фигыльләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
•аваз ияртемнәре һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләм дә куллана белергә;
•хәбәрлек сүзләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
•бәйлек һәм бәйлек сүзләрне белергә, аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
•теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
•кисәкчәләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
•ымлыклар һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә; модаль сүзләр һәм аларга морфологик анализ ясый белергә, аларны аера белергә, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белергә;
•бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, бәйләнешле сөйләм төзи белергә;
•проект эшләрен башкара белергә;
•укыган текстның эчтәлеген сөйли алырга, телдән монолог, диалог төзи белергә;
•эш кәгазьләрен язарга белергә.

**Предметның эчтәлеге**

1.**6 нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау**

Фонетика. Сингармонизм законы. Сүз төркемнәре. Исем, сан, алмашлык, рәвеш, затланышлы фигыльләр, сыйфат сүз төркемнәрен кабатлау.

2.Сүз төркемнәре

**2.1.Фигыль**

Фигыль турында төшенчә. Фигыльләрнең ясалышы. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр. Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе, заман формалары, исемләшүе. Сыйфат фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы. Хәл фигыль, аның мәгънәләре, формалары, сөйләмдә кулланылышы. Исем фигыль, аның мәгънәсе, формасы, сөйләмдә кулланылышы. Аларның исемгә күчү очраклары. Татар телендә фигыльләрнең төп формасы буларак сүзлекләрдә бирелүе. Инфинитив, аның мәгънәсе, формалары, сөйләмдә дөрес кулланылышы һәм дәрес язылышы. Татар телендә ярдәмче фигыльләрнең кулланылышы. Кайбер мөстәкыйль мәгънәле фигыльләрнең ярдәмче фигыль буларак кулланылу очраклары. Фигыльләргә морфологик анализ ясау. Фигыльләрне кабатлау.

**2.2.Аваз ияртемнәре**

Аваз ияртемнәре турында төшенчә. Аларның ясалуы, морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Аваз ияртемнәре нигезендә сүзләр ясалышы. Аваз ияртемнәренә морфологик анализ ясау.

**2.3.Хәбәрлек сүзләр**

Хәбәрлек сүзләр турында төшенчә. Татар телендә хәбәрлек сүзләрнең тоткан урыны. Хәбәрлек сүзләрнең формалары һәм җөмләдә кулланылышы.

**2.4.Бәйлекләр**

Бәйлек турында төшенчә. Аларның сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләре. Бәйлекләрне төркемләү. Бәйлек сүзләр, аларның формалары, җөмләдә кулланылышы. Бәйлекләргә морфологик характеристика бирү. Бәйлек сүзләр.

**2.5.Теркәгечләр**

Теркәгечләр турында гомуми мәгълүмат бирү. Теркәгечләрне куллану үзенчәлекләре, аларның интонациягә бәйле булуы. Теркәгечләрне төркемләү. Татар һәм рус телләрендә теркәгечләрнең уртак яклары, җөмләдә кулланылышы.Теркәгечләрне морфологик яктан тикшерү.

**2.6.Кисәкчәләр**

Кисәкчәләр. Аларны мәгънәләре буенча төркемләү.Татар телендә кисәкчәләрнең дөрес язылышы. Кисәкчәләргә морфологик анализ ясау.

**2.7.Ымлыклар**

Ымлыклар. Аларның ясалу үзенчәлекләре һәм сойләмдә кулланылышы.

**2.8.Модаль сүзләр**

Модаль сүзләр турында төшенчә. Аларның җөмләдә кулланылышы.

**3.Морфология буенча үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау**

Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәре. Аларның җөмләдә кулланылышы. Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау.

**4.Бәйләнешле сөйләм үстерү**

**Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары**

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение яздырып тикшереп була; сорауларга язма рәвештә җавап алу да уңай нәтиҗә бирә. Сораулар укыган әсәр, аерым текст, рәсем яки караган фильмнар буенча тәкъдим ителә. Бу очракта язма эшнең күләме һәр сыйныфның изложение күләменнән артмый. Укытучы, эшне бәяләгәндә, түбәндәге таләпләрне истә тотарга тиеш: җавапның тулы, төгәл, дөрес булуы, сөйләмнең стилистик яктан камиллеге, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталылыгы.

**Сорауларга җавап язуны бәяләү**

Барлык сорауларга да дөрес җавап бирелсә, «5» ле куела (1 сөйләм хатасы яки 1пунктуацион хата булырга мөмкин).

Сорауларга дөрес җавап бирелсә, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 орфографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрелсә, «4» ле куела.

Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәләре сизелсә, 3 сөйләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хата булса, «3» ле куела.

Җавапларның яртысы дөрес булмаса, сөйләм хаталары 3 тән артса, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

Татар теле дәресләрендә укытучы укучыларның язу тизлегенә дә игътибар итәргә тиеш. Акрынрак язган укучылар белән аерым эшләргә кирәк. Бу эшне оештыру өчен, сүзләр һәм хәрефләрнең саны түбәндәгечә тәкъдим ителә.

**Сүзлек диктантының күләме -** 7 нчы сыйныф –22 –30 сүз

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1.Пөхтә итеп язылган, хатасы булмаган эшкә «5» ле куела.
2.1-2 орфографик хаталы эшкә «4» ле куела.
3.3-4 орфографик хаталы эшкә «3» ле куела.
4.5 һәм аннан күбрәк хаталы эшкә «2» ле куела.

| No | Дәрес темасы | Сәг. саны | Укучы эшчәнлегенә характеристика | Көтелгән нәтиҗәләр | | | Өйгә эш | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Предмет | Метапредмет | Шәхескә кагылышлы | | план | фак |
| 1 | 6 нчы сыйныфта өйрәнгәннәрне кабатлау. Тест эшләү | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш, төркемнәрдә эшләү | Үтелгән сүз төркемен искә төшерү, аларны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү | **ТБУУГ**:үзеңнең белем системасында ориентлаша белү, текстган фактик мәгълүматны аерып алу.**КУУГ:**үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү.**РУУГ**: максатка ирешү юлларын планлаштыру. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләрең не белү-белмәү чикләрен билгеләү | Өй эше бирелмәде | 5.09 | 5.09 |
| 2 | Сүз төркемнәре. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр | 1 | Затланышлы һәм затланышсыз фигыль төркемчәләренә игъти бар итү, рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш | “Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр” төшенчәсен белү, аларны аера белү, телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** күренешләрне чагыштыру, уку проблемасын чишү өчен план яки модель төзү. **КУУГ:** телдән сөйләү барышында әдәби тел нормаларын үтәү.**РУУГ:** мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Татар теленең байлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | 63 нче күнегүне язып эшләргә | 11.09 | 11.09 |
| 3 | Күчереп язу | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Сүзләрне дөрес язу; сүзләрне төркемнәр буенча аера белү | **ТБУУГ:** белемнәрне структуралаштыру **КУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. **РУУГ:** хаталарны табу, төзәтү. | Үзбәягә сәләтле булу | Кушымчалар куеп, җөмләләрне язарга | 19.09 | 19.09 |
| 4 | Сыйфат фигыль. | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү | Хәзерге заман сыйфат фигыльләрнең | **ТБУУГ:** фактик мәгълүматның төп билгеләрен аерып | Татар теленең байлыгын, | 78 нче күнегүне | 25.09 | 25.09 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Хәзерге заман сыйфат фигыль | | өстендә язма эш, телдән эш | төп билгеләрен аера белү, телдән, язма сөйләмдә куллана, аларга морфологик анализ ясый белү. | чыгару. **КУУГ:** үз фикерең не тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. **РУУГ:** мәгълүмат туп лауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | матурлыгын аңлау, туган тел белән горурлану; сүзләрне урынлы куллана белү | язып эшләргә | | |
| 5 | Үткән заман сыйфат фигыль | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү өстендә язма эш, телдән эш | "Үткән заман сый фат фигыль," төшен чәләренең мәгънәсе нә төшенү, үткән за ман сыйфат фигыль ләрне таный, кулла на, аларга морфоло гик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** үрнәк буенча эш ли белү; төп билгеләрен ае рып чыгару.**КУУГ:** үз фике реңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. **РУУГ:** мәгълү мат туплауда узара хезмәт тәшлек инициативасы күрсәтү. | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңлау; сөйләмне камилләштерүгә омтылу. | 86 нчы күнегүне язып эшләргә | 2.10 | 2.10 |
| 6 | Киләчәк заман сыйфат фигыль | 1 | Рус теленә тәрҗемә итү өстендә язма эш, телдән эш | "Киләчәк заман сый фат фигыль" төшен чәсенең эчтәлеген белү, киләчәк заман сыйфат фигыльләрне таный, куллана һәм аларга морфологик анализ ясый белү. | **ТБУУГ**: белешмәлекләр дән, сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны эзли белү. **КУУГ**: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. **РУУГ**: мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Укуга кызыксыну уяту; туган телгә хөрмәт хисе булдыру. | 99 нчы күнегүне язып эшләргә | 11.10 | 11.10 |
| 7 | Сыйфат фигыльне кабатлау. | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Сыйфат фигыль буенча белемнәрне системалаштыру. Аларга морфологик анализ ясый белү. | **ТБУУГ:** төп билгеләрне ае рып чыгару**. КУУГ:** үз фи кереңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү.**РУУГ**: мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, эшеңнең уңыш лылыгын билгеләү | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләрең не белү-белмәү чикләрен билгеләү. | "Мин циркта" дигән темага хикәя язарга | 25.10 | 25.10 |
| 8 | Контроль күчереп язу | 1 | Язма эш башкару. Эшчәнлеккә | Татар теленнән алган белемнәрне гомумиләштерү. | **ТБУУГ:** язма эшне баш карганда татар әдәби теле нең нормаларын саклау һәм | Әхлак сыйфатлары булдыру. | 113 нче күнегүне язып | 8.11 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | нәтиҗә ясау. | | дөрес язу кагыйдәләрен үтәү, тәкъдим ителгән әдә би текстны язма формада күрсәтә алу; башлангыч текстның темасыннан чы гып, логик бәйләнешне сак лый алу. **КУУГ:** үз фике реңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү. **РУУГ:** үз эш чәнлегенең максатка ирешү дә ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуына төшенү | | эшләргә | | |
| 9 | Хәл фигыль, аның төрләре | 1 | Хәл фигыльләрне рус теленә тәрҗемә итү, күнегүләр өстендә язма эш, телдән эш | “Хәл фигыль” төшенчәләренең эчтәлеген белү. Хәл фигыльләрне аера, сөйләмдә куллана һәм аларга морфологик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** күренешнең уртак һәм аермалы якларын ае рып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.**КУУГ:** тел дән сөйләү барышында та тар әдәби теленең нормала рын үтәү. Үз фикереңне ту лы һәм төгәл итеп әйтә бе лү. **РУУГ:** мәгълүмат туп лауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләрең не белү-белмәү чикләрен чамалау. | 119 нчы күнегүне язып эшләргә | 22.11 | |
| 10 | Хәл фигыльнең төрләре, җөмләдә кулланылышы | 1 | Хәл фигыльнең төрләрен истә калдыру, җөмләдә кулланылышын өйрәнү | “Хәл фигыль” төшенчәләренең эчтәлеген белү. Хәл фигыльләрнең төрләрен таный һәм аера, язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** фактик мәгълүмат ның уртак һәм аермалы як ларын аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру. **КУУГ:** үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү. **РУУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчән леген оештыруда хезмәт | Укуга уңай караш тәрбияләү | 146 нчы күнегүне язып эшләргә | 6.12 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | тәшлек итү. | | | | |
| 11 | Хәл фигыль темасын күнегүләр һәм тестлар өстендә ныгыту | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | Хәл фигыльләргә морфологик анализ ясау тәртибен белү; сүзгә морфологик анализ ясау (телдән һәм язма). | **ТБУУГ:** фактик мәгълүмат турында белгәннәрне искә төшерү һәм кабатлау, төп билгеләрен аерып чыгару. **КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. **РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. | Эшне эзлекле эшләү сәләте булдыру | Җөмләләр эзләп язарга | 22.12 | |
| 12 | Владимир Кочһтковның “Кыш килде” картинасы | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Сочинение текстында гы сүзләрне орфогра фик, пунктацион нор маларны истә тотып дөрес язу, грамма тик биремне башкара белү. | **ТБУУГ:** белемнәрне структуралаштыру. **КУУГ:** башкаларны тыңлый белү. **РУУГ:** уку мәсьәләсен кую һәм чишү. | Эшне нәтиҗәле итеп башкаруга омтылыш булу | Үткәннәр не тулысынча кабатлап чыгарга | 17. 01 | |
| 13 | Исем фигыль, кайбер исем фигыльләрнең исемгә күчүе | 1 | Исемнәрнең һәм исем фигыльләр нең лексик-грам матик мәгънәсе нә һәм морфоло гик үзенчәлекло ренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, кү негүләр өстендә язма эш | “Исемгә күчү” төшенчәсенең мәгънәсенә төшенү. Сүз төркеме буларак, исемнәрне һәм исем фигыльләрне таный, куллана, аларны аера һәм аларга морфологик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** төп билгеләрне аерып чыгару; фикерләүнең логик чылбырын төзү. **КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. **РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | Телне өйрәнүгә кызыксыну булу; үзеңнең сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу | 163 нче күнегүне язып эшләргә | 31.01 | |
| 14 | Исем | 1 | Исем фигыль | Исем фигыльләрне | **ТБУУГ:** төп билгеләрен | Мөстәкыйль | 169 нчы | 14.02 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фигыльләрне кабатлау | | ләрнең лексик-грамматик мәгъ нәсенә, морфо логик үзенчәлек ләренә игътибар итү, рус теленә тәрҗемә итү, кү негүләр өстендә язма | аера белү, аларга морфологик анализ ясый белү. | аерып белү. **КУУГ:** үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп дәлилли белү. **РУУГ:** мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү | эшләү күнекмәреңне ныгыту | күнегүне язып эшләргә | | |
| 15 | Инфинив. Инфинитивның дөрес язылышы | 1 | Телдән эш, күнегүләр өстендә язма эш | “Инфинитив” төшенчәләренең мәгънәсенә төшенү. Инфинитивны таный һәм куллана белү, аларга морфологик анализ ясый белү | **ТБУУГ:** фактик мәгълүмат тан чыгып, кагыйдә форма лаштыру. **КУУГ:** үз фикер ләреңне һәм җавапларны телдән матур, дөрес итеп әйтә белү. **РУУГ:** максатка ирешү юлларын планлаштыру. | Үзмаксат кую, үз мөмкинлекләрең не белү-белмәү чикләрен чамалау | 178-179 нчы күнегүләр не язып эшләргә | 13.03 | |
| 16 | Контроль күчереп язу | 1 | Үз-үзеңә контроль ясау | Диктант текстындагы сүзләрне дөрес язу һәм грамматик биремне башкару | **ТБУУГ:** орфографик, пунк тацион кагыйдәләрдән чы гып, дөрес яза белү **КУУГ**: ишетеп аңлау, фикереңне җиткерә белү.**РУУГ:** инди видуаль эшне дөрес бәяли белү. | Язма сөйләмеңне камилләштерү | Татар әдәбияты китабынна н ярдәмче фигыльләр кергән 10 җөмлә язып алырга | 27.03 | |
| 17 | Ел буена үткәннәрне гомумиләште реп кабатлау. Уку елына йомгак | 1 | Мисалларны уку, сорауларга җавап бирү, сүзләрне сүз төркемнәренә бүлеп язу. | Мөстәкыйль сүз төр кемнәрен белү, алар га морфологик ана лиз ясый белү, язма яки телдән сөйләмдә куллана белү. | **ТБУУГ:** үзеңнең белем сис темасында ориентлаша бе лү. **КУУГ:** сыйныфташлар белән уку эшчәнлегендә оештыруда хезмәттәшлек итү. **РУУГ:** үзконтроль. | Үз уңышларың ның (уңышсыз лыкларыңның) сәбәпләре хакында фикер йөртү. | Үткәннәр не тулысынча кабатлап чыгарга | 17.04 | |